КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 июнь г.Казань № 767

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына карамаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасының дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүче һәм аларга хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хакына тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен эш стажын исәпләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 11 сентябрь, 463 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына карамаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасының дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүче һәм аларга хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хакына тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен эш стажын исәпләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 11 сентябрь, 463 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына карамаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасының дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүче һәм аларга хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына карамаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасының дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүче һәм аларга хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хакына тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен эш стажын исәпләү турындагы нигезләмәдә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 июнендәге ПУ-221 номерлы Указының 4 пунктында каралган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «органнарында» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта татар текстында «1 гыйнварыннан» сүзләреннән соң «2013 елның 31 мартына кадәр (31 мартны кертеп)» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «өстәмә түләүне исәпләү өчен» сүзләрен «айлык өстәмә түләүне исәпләү өчен» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен эш стажын исәпләгәндә бу Нигезләмәнең 1 пунктында каралган эш чорлары бергә кушып исәпләнә.»;

3 пункттагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эш стажы хезмәт кенәгәсе һәм (яки) законнар белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмә белән раслана.»;

4 пунктта «өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин